ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» ноябрь 2024 ел № 10

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге составына керүче Яссы-Тугай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26, 92 маддәләре нигезендә, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында»гы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Яссы-Тугай торак пункты, Тукай урамы, 41в йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең Яссы-Тугай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2025 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге Яссы-Тугай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия армиясе сафларында хезмәт итүче хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яссы-Тугай торак пунктының юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (төзү, реконструкцияләү, асфальтлау, ремонтлау, вак таш салу, ПГС салу, ташу, төзелеш материалларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына Яссы-Тугай торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Димтамак авыл җирлеге башлыгы Җ.Ә.Хөснетдинов